# КАРАР

**Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Дурт-Мунча авыл җирлеге составына керүче Дурт-Мунча торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында**

**16.11.2020** **№ 2**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2019 елның 14 нче ноябрендә булып узган гражданнар җыены нәтиҗәләре нигезендә сорау буенча беркетмә төзелде: "Сез 2021 елда Дурт-Мунча авыл җирлегенең Дурт-Мунча торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым акчаларын кертүгә, көндезге формада белем алучы студентлардан, I төркем инвалидларыннан тыш, һәм алдагы эшләрне башкару буенча җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны җибәрүгә килешәсезме:

- Молодежная урамындагы су үткәргечен ремонтлау, 325 м;
- территорияне чабу;
- санкцияләнмәгән чүплекләрне ликвидацияләү;
- Сабантуй үткәрү урынын төзекләндерү;
- урам яктырткычларын светодиодлы лампочкаларга алыштыру һәм ремонтлау;
- Үзәк урамындагы, Заречная урамындагы юл чокырларны ремонтлау.

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:
сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә гражданнар җыенында катнашучы 194 кеше, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар саны 147 кеше кертелгән.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«Әйе» позициясе өчен 139 җыенда катнашучы тавыш бирде;

«Юк» позициясе өчен 8 җыенда катнашучы тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар итте:

1. Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Дурт-Мунча авыл җирлегенең Дурт-Мунча торак пунктында гражданнар җыенын узган дип танырга, халык җыены нәтиҗәләре-дөрес.

2. Түбәндәге сорау буенча карар кабул итәргә: «Сез 2021 елда Дурт-Мунча авыл җирлегенең Дурт-Мунча торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым акчаларын кертүгә, көндезге формада белем алучы студентлардан, I төркем инвалидларыннан тыш, һәм алдагы эшләрне башкару буенча җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны җибәрүгә килешәсезме:

- Молодежная урамындагы су үткәргечен ремонтлау, 325 м;
- территорияне чабу;
- санкцияләнмәгән чүплекләрне ликвидацияләү;

- Сабантуй үткәрү урынын төзекләндерү;

-урам яктырткычларын светодиодлы лампочкаларга алыштыру һәм ремонтлау;

-Үзәк урамындагы, Заречная урамындагы юл чокырларны ремонтлау. кабул ителгән.

3. Әлеге карарны мәгълүмат стендларында бастырып чыгарырга, «Татарстан Республикасы Хокукый мәгълүматның рәсми порталында» (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм Зәй муниципаль районының рәсми сайтында «Авыл җирлекләре» бүлегендә урнаштырырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Дурт-Мунча авыл җирлеге башлыгы,
Совет Рәисе ______________________ Р.Т.Ситдиков